Гыйнвар - май, 2020

# Гимназия сулышы №3

## 25 нче гимназия укучылары газетасы

**Хәрби-патриотик чара**

19 нчы февральдә гимназиянең спорт залында Ватан сакчылары көне уңаеннан һәм Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган зур чара үткәрелде. Бу- 9-11 сыйныфлар катнашында җырлап стройда атлау иде.

Чарага жюри буларак озак еллар гимназиядә физик тәрбия укытучысы булып эшләгән мәгариф ветераны Әшрәфҗанов Тәлгать Закир улы, гимназиянең директор урынбасары Мишина В.Б., тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Куркина Н.М. һәм Сириядә хәрби хезмәттә

булган Хисаметдинов И. чакырылган иде. Барлык сыйныфларның сафта йөрешен караганнан соң жюри нәтиҗәләрне игълан итте. 1-урынны 11 А сыйныфы, 2-урынны 10 А сыйныфы, 3 урынны 10 Б һәм 9 А сыйныфлары алды. Баранкова Дана



**Бәйрәм белән!**

**«Ватан сакчылары» көне уңаеннан гимназиядә укучы малайларны, ир-ат укытучыларын бәйрәм белән котладык.**

Гимназиядә озак еллар дәвамында физик тәрбия укытучысы булып эшләүче мәгариф ветераны, оста

шахматчы Гаранин Виктор Павел улын; тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ) укытучысы, гимназиядә хәрби-патриотик эшне алып баручы Мәрданшин Илнур  Мулланур улын;



физик тәрбия укытучысы, шәһәр, республика күләмендә спорт ярышларында актив катнашучы Соколов Владимир Вячеслав улын; технология укытучысы, алтын куллы Попов Анатолий Иван улын; инглиз теле укытучысы Пилипенко Богдан Андрей улын « Ватан сакчылары» көне белән чын күңелдән котлыйбыз. Аларга җаваплы һәм мактаулы хезмәтләрендә уңышлар һәм сабырлык , бәхет, сәламәтлек, иминлек телибез! Бакирова Алия

**Гимназиядә «Туган тел» көне**

«Халыкара туган тел көне»ндә барлык телләр дә тигез дәрәҗәдә итеп таныла.Чөнки һәр кешегә тел мәңге сакларга тиешле байлык булып тора. Туган тел – беренче мәртәбә әйләнә-тирәне танып белергә, һәр нәрсәне үз исеме белән әйтергә өйрәтүче, шулай ук әти-әниебез, гаилә белән аңлашу һәм дуслар, мәктәп белән аралашуда



ярдәм итүче тел ул.
Гимназиядә «Туган тел көне» нә багышланган чарада һәр халыкның үзенчәлекле телен, милли биюләрен, шигырьләр, җырларын гимназия укучылары үз чыгышларында күрсәттеләр. Бәйрәмгә «Кама таңнары» әдәби-берләшмәсеннән килгән кунак шагыйрә Ф.И. залда утыручы гимназия укучыларына мөрәҗәгать итеп болай диде: « Кадерле балалар! Барыгызны да «Туган тел көне» белән котлыйм. Нинди милләттән булуыгызга карамастан һәркайсыгыз үз туган телегезне өйрәнегез, туган телегездә сөйләшегез, туган телегезне саклагыз!» Алексеева Лариса

**Республика юбилеен каршылыйбыз**

ТАССР ның 100 еллыгына багышлап гимназиядә сыйныф сәгатьләре, тематик викториналар үткәрелде. Мәсәлән, туган тел һәм әдәбият укытучысы Шәрәпова

Нурия Нәҗип кызы 6 Г сыйныфы укучылары белән Татарстанда яшәүче тугандаш халыкларның милли киемнәре һәм милли бәйрәмнәренә багышланган викторина үткәрде. Укучылар күпмилләтле Татарстан турында белемнәрен күрсәттеләр. Садреева Эльмира



**Иҗади бәйге**

5мартта гимназиядә рус язучысы А.П.Чеховның тууына 160 еллыгына багышланган IVрегиональ иҗади конкурс үткәрелде. Конкурста 400 гә якын укучы катнашты. Алар Алабуга, Актаныш, Баулы, Тукай, Норлат районнарынан һәм Түбән Кама шәһәре мәктәпләреннән һәм колледжларыннан иде. Быелгы конкурста 2020 елның тарихи даталары - Бөек Җиңүнең 75 еллыгына һәм ТАССР ның 100 еллыгына багышланган сәхнә әсәрләре инсценировкалары белән чыгыш ясаучы укучылар коллективлары күп булды. 22 гимназия укучыларының «Сугыш балалары» дип аталган сәхнә күренеше залда утыручыларга аеруча тәэсир итте. Кыска хикәя жанрына караган иҗади конкурста, А.П.Чехов әсәрләрен рус һәм татар телләрендә яттан сөйләү конкурсында һәм язучының әсәрләре буенча ясалган рәсемнәр конкурсында җиңүчеләр арасында гимназия укучылары күп булды. Якупова Гүзәл

**Очрашу мизгелләре**

Гыйнвар ахырында гимназиядә традиция буенча классташлар очрашуы булып үтте. Актлар залында гимназияне төрле елларда тәмамлаган 150 егет һәм кыз үзләренең яраткан укытучылары, дистә ел дәвамында бергә укыган клсссташлары белән очрашты.



Бүгенге көндә институт һәм колледжларда белем алучы егетләр-кызлар мәктәп хатирәләре белән уртаклаштылар.

Гимназия кунаклары өчен «Аллегро» һәм «Бию ритмнары» бию коллективлары, 9-11 сыйныф укучылары катнашында вокаль-инструменталь ансамбль чыгыш





ясады.

**Дистанцион уку, онлайн-дәресләр**



Дүртенче чирек бөтендөньяны куркуга салган короновирус пандемиясе аркасында мәгариф һәм белем бирү тармагында беренче тапкыр дистанцион уку рәвешендә башланып китте. Укуның беренче атнасы укучылар һәм укытучылар өчен җиңел генә бирелмәде: интернетта өзеклекләр килеп чыкты, смартфоннар, планшетлар сафтан чыкты. Укытучылар дәресләрне яңа интернет платформаларында (ZOOM, Scype) үткәрделәр.



Дистанцион уку барышында күп балалы һәм ярдәмгә мохтаҗ гаиләләрдә укучыларга ноутбуклар бирелде. Гимназиянең барлык укучыларына азык-төлек җыелмалары өләшенде.

**Чыгарылыш 2020**

Ниһаять, короновирус пандемиясе аркасында бер айга сонга калган БДИ лар артта калды. Быел гимназиянең 30 укучысы 11сыйныфны тәмамлап, кулларына аттестат алып зур тормыш юлына аяк атлады. Бик тиздән алар югары уку йортлары студентлары буларак укуларын дәвам итәрләр. Уңышлар, сезгә унберенчеләр!

